**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5021**
**13.06.2023**

«Елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» шәһәр конкурсы үткәрү турында

Яр Чаллы шәһәрендә территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең тотрыклы эше һәм үсеше өчен уңайлы шартлар формалаштыру максатында, Башкарма комитетның 2020 елның 30 октябрендәге 5734 номерлы карары белән расланган «2021-2023 елларга Яр Чаллы шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәсен үстерү» муниципаль программасы кысаларында, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» шәһәр конкурсын (алга таба – конкурс) 2023 елның 19 июненнән 2023 елның 24 июленә кадәр үткәрергә.
2. Расларга:
1) шәһәр конкурсы турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;
2) конкурс комиссиясе составын, 2 нче кушымтада каралганча.
3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурсны оештыру һәм аңа йомгак ясау чыгымнарын финанслауны шәһәр бюджетының «Башка гомумдәүләт мәсьәләләр» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 350 000 (өч йөз илле мең) сум күләмендә тәэмин итәргә.
4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 13 июнендәге
5021 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе»
шәһәр конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге «Елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» шәһәр конкурсы (алга таба – конкурс) турында нигезләмә конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурс ел саен Башкарма комитет карары белән билгеләнгән срокларда үткәрелә.

3. Конкурсны оештыручы булып Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (алга таба – идарә) тора.

4. Конкурс территориаль иҗтимагый үзидарә эшенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, халыкның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча үз инициативаларын гамәлгә ашыруда эшлекле һәм социаль активлыгын үстерүгә һәм стимуллаштыруга, йорт яны территорияләрен карап тоту, төзекләндерү һәм яшелләндерүдә халык инициативасын үстерүгә, халыкны торак фонд сакланышын тәэмин итү эшендә катнашуга җәлеп итүгә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү өчен уңайлырак шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

5. Конкурсның бурычлары:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә ТИҮ территориясен төзекләндерү буенча, халыкның ялының сыйфатын күтәрүгә ярдәм итү буенча, шәһәр территориясендә яшәүче халык белән эшләү буенча эшчәнлекне аеруча нәтиҗәле гамәлгә ашыра торган территориаль иҗтимагый үзидарәләрне (алга таба – ТИҮ) ачыклау;

2) уңай эш тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату.

2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү

6. Конкурста катнашучы булып, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге ТИҮ, конкурста катнашуга заявка (алга таба – заявкалар) биргән актив ТИҮ әгъзалары (алга таба – катнашучылар) тора.

7. Конкурста катнашу өчен, катнашучылар 2023 елның 3 июленә кадәр Башкарма комитетның тиешле район хакимиятенә түбәндәге документларны тапшыралар:

1) конкурста катнашуга заявка;

2) узган календарь ел өчен ТИҮ эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат (төрле формада бирелә: видеоматериаллар, фоторәсемнәр, массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан мәкаләләр тезмәсе һ.б.);

Заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң барлык конкурс материаллары конкурс комиссиясенә (алга таба – конкурс комиссиясе) тапшырыла.

8. Конкурста катнашуга заявканы кире кагу өчен нигез булып документларның тулы пакеты тапшырылмау, бирелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы, шулай ук документларның заявка бирү өчен билгеләнгән датадан соң бирелүе тора.

9. Конкурсны оештыручылар конкурста катнашучыларның ризалыгы буенча, тапшырылган конкурс материалларын массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм Интернет челтәрендә урнаштыру өчен файдалану хокукына ия.

10. Конкурс комиссиясенең составы Башкарма комитет карары белән раслана.

11. Конкурс комиссиясе:

1) конкурска тапшырылган материалларны карап тикшерә;

2) конкурста катнашуга заявканы кабул итү яки кире кагу турында карар чыгара;

3) тапшырылган материаллар буенча баллар куя;

4) конкурска йомгак ясый һәм җиңүчеләрне билгели.

12. Конкурс комиссиясе әгъзаларының өчтән ике өлеше утырышта катнашкан очракта, ул тулы хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе карары гади күпчелек тавыш нигезендә кабул ителә. Тавышлар саны тигез (50%) булган очракта, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

13. Конкурс түбәндәге очракларда үтмәде дип таныла:

1) конкурста катнашуга заявкалар булмау;

2) конкурста катнашуга бер заявка керү.

## 3 бүлек. Конкурсның бәяләү критерийлары

14. Конкурс комиссиясе тапшырылган заявкаларны карап тикшерә һәм конкурска тәкъдим ителгән мәгълүматны, әлеге нигезләмәгә кушымта нигезендә, бәяләү кәгазе буенча бәяли.

15. «Иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарә» номинациясендә бәяләү критерийлары:

1) халыкны актуаль мәсьәләләр буенча укыту;

2) «Интернет» челтәрендә ТИҮ эшчәнлеген яктырту:

- социаль челтәрләрдәге битләр (200 һәм аннан күбрәк язылучы);

- төрле мессенджерларда әңгәмәләр (әңгәмәдә 20 һәм аннан күбрәк кеше катнашу);

3) халыкка комплекстагы яңалыклар, вакыйгалар турында мәгълүмат җиткерү (шул исәптән территориядә планлаштырылган эшләр турында мәгълүмат бирү);

4) ТИҮ территориясендә мәдәни-массакүләм һәм спорт чаралары үткәрү;

5) хокук бозуларны кисәтүгә, җәмәгать тәртибен саклауга (шул исәптән балигъ булмаганнарга алкоголь һәм тәмәке продукциясе сату фактларын ачыклауга) юнәлдерелгән чараларда катнашу;

6) ташландык, хуҗасыз һәм комплектлары алынган транспорт чаралары хуҗаларын ачыклау буенча эшләр үткәрү;

7) киләсе елга территорияне төзекләндерү буенча ТИҮ эшен планлаштыру;

8) ТИҮ территориясен төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча сезонлы эшләр оештыру:

- өмәләр оештыру;

- агачлар утырту;

9) ТИҮ территориясендә «Иң яхшы йорт, ишегалды (урам), подъезд, чәчәк бакчасы» исеменә конкурслар үткәрү;

10) ТИҮ территориясендә урнашкан идарә оешмалары белән үзара хезмәттәшлек;

11) җәлеп ителгән акчаларның гомуми суммасы (бюджет/бюджеттан тыш);

12) ТИҮнең төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашуы;

13) эшчәнлекне массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту.

16. Баллар суммасы конкурс комиссиясенең барлык әгъзалары тарафыннан барлык критерийлар буенча билгеләнә, конкурсның йомгаклау билгесе һәр катнашучы буенча куела. Бәяләү йомгаклары буенча катнашучылар рейтингы төзелә.

17. Конкурс комиссиясе карары буенча, проектларны бәяләү өчен махсус белемле һәм квалификацияле экспертлар җәлеп ителергә мөмкин.

## 4 бүлек. Конкурска йомгак ясау

18. Карар конкурсның һәр катнашучысына карата ачык тавыш бирү юлы белән конкурс комиссиясе әгъзаларының күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә һәм конкурс комиссиясенең утырышта катнашкан әгъзалары тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

19. Конкурсны үткәрү өчен гомуми фонд 350 000,00 (өч йөз илле мең) сум тәшкил итә.

20. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс җиңүчеләрен - ТИҮләрне бүләкләү өчен түбәндәге күләмдә грантлар бирү турында карар кабул ителә:

-50 000,00 (илле мең) сум күләмендә гран-при бирү;

- беренче урынны алган өч җиңүченең һәркайсына 30 000 (утыз мең) сум;

- икенче урынны алган өч җиңүченең һәркайсына 25 000 (егерме биш мең) сум;

-өченче урынны алган өч җиңүченең һәркайсына 20 000 (егерме мең) сум;

-дүртенче урынны алган өч җиңүченең һәркайсына 15 000 (унбиш мең) сум;

-бишенче урынны алган өч җиңүченең һәркайсына 10 000 (ун мең) сум;

21. Конкурска нәтиҗәләр 2023 елның 24 июленә кадәр ясала.

## 5 бүлек. Грант бирү

22. Конкурс комиссиясенең карары нигезендә, Башкарма комитет тиешле районнарның ТИҮ ассоциацияләре белән конкурс җиңүчеләренә грант бирү турында шартнамә төзи.

23. Конкурс җиңүчеләренә грант акчалары бирү турында шартнамә нигезендә, тиешле районнарның ТИҮ ассоциацияләре шәһәр конкурсында җиңүчеләр белән ТИҮ рәисен һәм активын бүләкләүгә грант акчалары бирү турында шартнамә төзи.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

«Елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» шәһәр конкурсы турында нигезләмәгә кушымта

Бәяләү кәгазе

| № т/б | Күрсәткеч | Зурлыгы | Күрсәткечләр буенча аңлатмалар, мәгълүмат чыганагы | Күрсәткеч зурлыгын бәяләү (баллар) | Фактик баллар | Максималь мөмкин булган баллар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Халыкны актуаль мәсьәләләр буенча укыту | чаралар саны, үткәрү форматы, датасы | Фотоматериаллар | 1 дән 5 кә кадәр чара– 20 балл | | 100 |
| | | | | 6 дан 10га кадәр чара– 30 балл | | |
| | | | | 11 дән 15 кә кадәр чара–60 балл | | |
| | | | | 16 дан 20 гә кадәр чара – 100 балл | | |
| 2 | «Интернет» челтәрендә ТИҮ эшчәнлеген яктырту:<br>- социаль челтәрләрдәге битләр (200 һәм аннан күбрәк язылучы);<br>- төрле мессенджерларда әңгәмәләр (әңгәмәдә 20 һәм аннан күбрәк кеше); | Социаль челтәрдә һәм мессенджерларда битләр һәм әңгәмәләр булу | Сылтамалар, скриншотлар | 1-3 социаль челтәрдә теркәлү –<br>50 балл | | 100 |
| | | | | 4 һәм күбрәк социаль челтәрдә теркәлү –<br>100 балл | | |
| 3 | Халыкка комплекстагы яңалыклар, вакыйгалар турында мәгълүмат җиткерү (шул исәптән территориядә планлаштырылган эшләр турында мәгълүмат бирү); | Мәгълүмат стендларында мәгълүмат урнаштыру (шул исәптән социаль челтәрләр һәм мессенджерлар аша эшләү) | Фотоматериаллар, скриншотлар | Мәгълүмат бирү: | | 100 |
| | | | | 1-20 вакыйга турында– 25 балл | | |
| | | | | 21-40 вакыйга турында– 35 балл | | |
| | | | | 41-60 вакыйга турында – 65 балл | | |
| | | | | 61-80 вакыйга турында -100 балл | | |
| 4 | ТИҮ территориясендә мәдәни- | Чаралар саны, форматы, | Фото һәм видеоматериаллар | 1дән 5кә кадәр чара – 50 балл | | 100 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | массакүләм һәм спорт чаралары үткәрү | үткәрү датасы | | 6 һәм күбрәк чара – 100 балл | | |
| 5 | Хокук бозуларны кисәтүгә, җәмәгать тәртибен саклауга (шул исәптән балигъ булмаганнарга алкоголь һәм тәмәке продукциясе сату фактларын ачыклауга) юнәлдерелгән чараларда катнашу | рейдлар саны | Фотоматериаллар | 1 дән 5кә кадәр рейд – 10 балл<br>6 дан 10га кадәр рейд – 30 балл<br>11 дән 15кә кадәр рейд – 60 балл<br>16 дан 20гә кадәр рейд – 100 балл | | 100 |
| 6 | Ташландык, хуҗасыз һәм комплектлары алынган транспорт чаралары хуҗаларын ачыклау буенча эшләр үткәрү | ТИҮ территориясендә күрсәтелгән транспорт чаралары булу | Фотоматериаллар | 1 дән 4кә кадәр – 30 балл<br>5 һәм күбрәк - 100 балл | | 100 |
| 7 | Киләсе елга территорияне төзекләндерү буенча ТИҮ эшен планлаштыру | ТИҮнең эш планы булу | Тиешле район хакимияте белән килештерелгән расланган план | Әйе 100 балл<br>юк – 0 балл | | 100 |
| 8 | 8) ТИҮ территориясен төзекләндерү һәм санитар чистарту буенча сезонлы эшләр оештыру<br>өмәләр оештыру;<br>- агачлар утырту | Чаралар саны, форматы, үткәрү датасы | Фотоматериаллар | 1 дән 15 кә кадәр - 30 балл<br>16 һәм күбрәк - 100 балл | | 100 |
| 9 | ТИҮ территориясендә «Иң яхшы йорт, ишегалды (урам), подъезд, чәчәк бакчасы» исеменә конкурслар үткәрү | Исеме, үткәрү датасы | Фотоматериаллар | әйе – 100 балл<br>юк – 0 балл | | 100 |
| 10 | ТИҮ территориясендә урнашкан идарә оешмалары белән үзара хезмәттәшлек | Халыктан кергән заявкалар саны / башкарылганзаявкалар саны | Фотоматериаллар, башкарылган эшләр акты | 1 дән 20гә кадәр – 30 балл<br>21 һәм күбрәк - 100 балл | | 100 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 11 | Җәлеп ителгән акчаларның гомуми суммасы (бюджет/бюджет тан тыш) | мең сум | | Баллар җәлеп ителгән акча суммасыннан исәпләнә (һәр 50 мең сум саен – 5 балл) | | 100 |
| 12 | ТИҮнең төрле дәрәҗәдәге конкурсларда катнашуы | конкурслар ның саны, исеме | Дипломнар, грамоталар | Баллар катнашкан конкурсның дәрәҗәсе нигезендә ранжирлана:<br>- шәһәр – 10 балл<br>- республика – 20 балл<br>- федераль – 30 балл | | 100 |
| 13 | Массакүләм мәгълүмат чараларында эшчәнлекне яктырту | Публикация ләр һәм сюжетлар саны (урнаштыру датасы һәм чыганаклар ы) | Фото һәм видеоматериаллар | Публикацияләр һәм сюжетлар саны:<br>1 дән 5кә кадәр – 20 балл<br>6 дан 10 га кадәр– 25 балл<br>11 дән 15 кә кадәр – 50 балл<br>16 дан 20гә кадәр – 100 балл | | 100 |
| Барлыгы | | | | | | 1300 |
| Нәтиҗәлелек күрсәткече<br>*(фактик баллар/максималь мөмкин булган баллар)* | | | | | % | |